**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күлле-Киме авыл җирлеге Советы**

## КАРАР

**«29» июль 2025 ел** **№ 125**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендәге 105 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 397 статьясы, 2025 елның 17 июнендәге 02-08-02-2025 номерлы прокурор протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге

Советының 2019 елның 3 октябрендәге 105 номерлы «Җир салымы турында» карарына (20.01.2020 ел, № 121, 30.10.2020 ел, № 7, 30.01.2024 ел, № 91, 24.10.2024 ел, №104 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.Карарның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4.3 пунктчасы өстәргә:**
"4.3. Оешмалар-салым түләүчеләр салымны узган салым чорыннан соң килүче елның 28 февраленнән дә соңга калмыйча түләргә тиеш. Салым буенча аванс түләүләре оешмалар-салым түләүчеләр тарафыннан узган хисап чорыннан соң килүче айның 28 числосыннан да соңга калмыйча түләнергә тиеш".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы: Гәрәев Х.Х.